ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ

# КАРАР

«05» июнь 2024 ел №43-1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 февралендәге 21/1 номерлы карарына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 н омерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 февралендәге 21/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасында «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга;

2 бүлек 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның (җирлек башлыгы) хезмәтенә түләү айлык акчалата бүләкләү формасында башкарыла:

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) | Акчалата кызыксындыру түләве (сумнарда) |
|---|---|---|
| Җирлек Башлыгы | 18 260 | 19569 (12,86) |

4 бүлек 2 пунктта «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга, «2023 елның 1 гыйнвареннән» сүзләрен «2024 елның 1 июленнән» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлек 3 пунктны 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

| **Вазыйфа исеме** | **Хезмәткә түләүнең 12 төркеме (сумнарда)** |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 18 253 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 17 720 |
| Әйдәп баручы белгеч | 14 789 |
| 1 категорияле белгеч | 13 323 |

4 бүлек 3 пункт 4 пуктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы в.б. Р.М.Харрасова